Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Баграж-Никольский авыл Советы

# КАРАР

24 июнь 2025 ел № 125

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Баграж-Никольский авыл Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Баграж-Никольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә,

Баграж-Никольский авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Баграж-Никольский авыл Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Дальняя Ивановка авылы, Яшьләр урамы, 26 нчы йорт; Баграж-Никольский авылы, Үзәк урам, 31б йорты торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында аны кабул иткән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Баграж-Никольский авыл җирлеге башлыгы Н.М. Новиков